КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2024 ел, 17 сентябрь

г.Казань

№ 801

2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 17 сентябрь, 801 нче
карары белән расланды

2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына (алга таба – төбәк операторы) Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчасын алучы буларак Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

6. Субсидия алу өчен төбәк операторы субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

төбәк операторы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия

Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

төбәк операторы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

төбәк операторы БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

төбәк операторы әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

төбәк операторы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

төбәк операторының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

төбәк операторының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

төбәк операторы үзгәртеп оештыру (юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән, юридик затның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки төбәк операторының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

7. Субсидия алу өчен төбәк операторы Министрлыкка әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча төбәк операторы җитәкчесе (аның бурычларын үтәүче зат) тарафыннан имзаланган заявканы тапшыра, аңа түбәндәге документларны терки:

төбәк операторы җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан расланган субсидия акчасы исәбеннән гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган чыгымнар сметасы;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләре;

төбәк операторы җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) вәкаләтләренраслый торган документлар күчермәләре;

төбәк операторы җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имзаланган, әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү турында белешмә кәгазе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә төбәк операторы турында мәгълүмат, төбәк операторы тарафыннан бирелә торган заявка, субсидия бирү белән бәйле төбәк операторы турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

Документлар кәгазьдә һәм (яки) электрон чыганакларда бирелергә мөмкин.

Кәгазьдә бирелгән барлык документлар төгәл бастырылырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, төбәк операторы җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән (булган очракта) төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазь чыганакта бирелгән барлык заявкалар кәгазьләре тегелгән, номерланган булырга, төбәк операторы җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

Тапшырылган документларның һәм әлеге Тәртипнең бу пунктында һәм 8 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен төбәк операторы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Төбәк операторы, заявкасы белән бергә, үз теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

заявка бирү датасына кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакытта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтә күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында документ күчермәсен;

салым органы тарафыннан төбәк операторының килешү төзергә планлаштырыла торган айның 1енә карата бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычы булмавы яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмавы турында бирелгән белешмә кәгазе.

Төбәк операторы тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә карап тикшерә;

заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында төбәк операторына язма хәбәр бирә.

10. Төбәк операторына субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

төбәк операторының әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

төбәк операторы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

төбәк операторы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

11. Субсидия бирү Министрлык белән төбәк операторы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелә.

Килешүдә Министрлык белән төбәк операторы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шартлары һәм тәртибе булырга тиеш.

Килешү үз эченә төбәк операторы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә төбәк операторының ризалыгы.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта килешүгә килешүнең яңа шартларын килештергәндә яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында шарт кертелә.

Кирәк булганда Министрлык төбәк операторы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Килешүдә төбәк операторына, шулай ук төбәк операторы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы акчасы (югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда

(кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында шартлар бирелә.

13. Төбәк операторы кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылган очракта, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

14. 21. Субсидия, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучы ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

15. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре:

гражданхокукый шартнамәләр нигезендә җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү (хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләрне исәпкә алып);

судка дәгъва гаризалары биргәндә дәүләт пошлинасын түләү өлешендә суд чыгымнары.

16. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

граждан-хокукый шартнамәләр буенча эш шартларында хезмәткәрләрне җәлеп итү – 2024 елда кимендә 5 кеше;

бурычлыларга – күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләренә карата суд боерыкларын чыгару турында гаризалар җибәрү юлы белән шикаять-дәгъва бирү эшен оештыру – 2024 елда кимендә 1 300 гариза.

17. Төбәк операторы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы календарь көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

18. Министрлык тапшырылган хисапларны Министрлыкка кергән датадан бер эш көне эчендә теркәп бара. Министрлык субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны карап тикшерә, төбәк операторының хисапларын кабул итү турында яисә, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән яки финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашырганда ачыкланган хокук бозулар булган очракта, төбәк операторының хисапларын кабул итмәү турында карар кабул итә һәм, алынган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, төбәк операторына аларны кабул итү (кабул итүдән баш тарту) турында хәбәр итә.

19. Хисап финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган акчаның файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алучы Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, субсидия алучыдан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, бюджет законнары нигезендә субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешен юллау ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, Министрлык һәм оешма арасында мондый карар кабул ителгән көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

20. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

21. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечена ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

22. Төбәк операторы тарафыннан, шулай ук төбәк операторы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган (устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш), шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта төбәк операторы, шулай ук әлеге затлар алынган акчаны Министрлыкның язма таләбен алган көннән алып 30 календарь көн эчендә тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтара .

23. Әлеге Тәртипнең 27, 30 пунктлары нигезендә субсидия чараларын Татарстан Республикасы бюджеты керемена ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, вәкаләтле орган субсидия алучының алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган

көннән яки субсидия алучы алган һәм вәкаләтле органның язма таләбендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле рәвештә кире кайтару вакыты чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

24. Субсидиядән нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

__________________________________ ка (кә)

_______________________________________

(коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

__________________________________ тан (тән)

Теркәлү номеры: ____________

Заявка теркәлү датасы: ____________

2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирүгә
заявка

| Коммерциягә карамаган оешманың исеме | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Коммерциягә карамаган оешманың урнашу урыны,телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Әлеге заявка белән коммерциягә карамаган оешма Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 17 сентябрь, 801 нче карары белән расланган 2024 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияне бирү тәртибенең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Әлеге заявка белән коммерциягә карамаган оешма «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коммерциягә карамаган оешма турында, коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән заявка, субсидия бирүгә бәйле коммерциягә карамаган оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирүен раслый.

Кушымталар: 1.
2.

Заявка бирүче ______________________________/_________________________/___________
(коммерциягә карамаган оешма исеме) (җитәкченең фамилиясе, инициаллары) (имза)

_______________________________________